ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРКАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КЕРКӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 31 октябре №7

Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге Керкәле торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге Керкәле торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 19 ноябренә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2023 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлар тыш, һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тукай урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен

үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-территорияне механикалаштырылган һәм кулдан чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү:

-Керкәл торак т Совет урамы, Җәлил урамы янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру;

4) Ритуал хезмәтләрен һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру:

-Керкәле торак пунктындагы зират территориясендә (килешү буенча түләү) коры һәм чүп үләнен чабу, иске авия хәлендәгеагачларны кисү;

5) Ял вакытын оештыру өчен шартлар тудыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү:

- «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел»бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Совет урамы, 93 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы Л.И. Бигманов